РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«6» декабря 2023г. г. Альметьевск №265

**Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 28 декабрендәге 145 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 02 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 28 декабрендәге 145 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 30 мартындагы 166 номерлы, 2017 елның 05 маендагы 178 номерлы, 2017 елның 31 маендагы 184 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 196 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 238 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 267 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 284 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 366 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 398 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 14 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 96 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 158 номерлы, 2023 елның 29 мартындагы 209 номерлы, 2023 елның 11 августындагы 235 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 4 бүлекнең кушымтасында «Муниципаль хезмәткәрләргә класслы чиннар бирү, муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына»:

- 4.6 пунктның 4.6.1 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
- 4.10 пункты үз көчен югалткан дип танырга;
- 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, 4 бүлекнең 4.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына кирәкле барлык документлар белән сыйныф чинын бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Н.В. Парфилова).

Муниципаль район Башлыгы Т. Д. Нагуманов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА